**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БЕГИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Клубная д. 1, с. Бегишево, Заинский район, 423511

Клубная урамы, 1нче йорт, Бигеш авылы, Зәй районы, 423511

Телефон, факс 3-82-25. Электронный адрес: Beg.zai@tatar.ru, сайт: www.Begsp.ucoz.ru

**Постановление** **Карар**

**17.04.2018** **№ 5**

**«2015-2018 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең муниципаль программасы турында» 2015 елның 04 июнендәге 11 номерлы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. 2015 елның 04 июнендәге 11 номерлы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының "Бигеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Россия Федерациясе дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын), муниципаль программаларны

(ярдәмче программаларны) гамәлгә ашыру максатларында кабул ителә торган Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән шартлар нигезендә күрсәтелгән программаларда (ярдәмче программаларда) катнашуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бертигез керүе; »;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 8.1 пунктын өстәргә:

«8.1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү.

Ярдәм муниципаль мөлкәткә, шул исәптән җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелешләрне, корылмаларны, торак булмаган биналарны, җиһазларны, машиналарны, механизмнарны, җайланмаларны, транспорт чараларын, инвентарьларны, инструментларны, түләүле нигездә, түләүсез нигездә яисә ташламалы шартларда Россия Федерациясе дәүләт программалары (ярдәмче программалары), Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программалары (ярдәмче программалары) нигезендә дәүләт программалары (ярдәмче программалары), муниципаль программалар (ярдәмче программалар) нигезендә тапшыру рәвешендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән мөлкәт максатчан билгеләнеше буенча файдаланылырга тиеш.».

2. Карарны Бигеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет житәкчесе** **И.Р.Вәлиев.**